**СОВЕТ НИКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422627 с. Никольское,
ул. Центральная, д.35
тел: 4-31-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422627 Никольский авылы,
Үзәк урамы, 35 нчы йорт,
тел: 4-31-44

---

**2025 елның «16» июне** **29 номер**

# КАРАР

## Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ЗРТ номерлы 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге советы муниципаль берәмлеге уставының 13 маддәсенең 3.3 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Камская новь» газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Никольский**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **А.Н.Пашагин**